# Кече һәм урта сыйныф укучыларын бердәм дәүләт имтиханына әзерләү

Бөгелмә шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Гыйләҗева Г.Л.

***6. Кайтчак*** **фигылен зат-санда төрләндер**

**5. Киләчәк заман хикәя фигыль нәрсәне белдерә?**

Сөйләгән вакытта эшләнгән эшне белдерә

Сөйләп торган вакыттан соң булачак эшне белдерә

Сөйләгән вакытка кадәр булган эшне белдерә

**4.Үткән заман хикәя фигыль кушымчаларын күрсәтегез**

-ачак/-әчәк

-а/-ә, -ый/-и -ар/әр

-ды/де, -ты/-те

**3. Хәзерге заман хикәя фигыль ничек ясала?**

-а/-ә, -ый/-и кушымчалары ялганып ясала

-ган/-гән, -кан/-кән кушымчалары ялганып ясала

-ыр/-ер, -р кушымчалары ялгап ясала

**2.Фигыльләр нәрсәләрдә төрләнәләр?**

Килешләрдә, саннарда

Зат-санда, заманда

Заманнарда

**1. Фигыльләр нәрсәне белдерәләр?**

Предметның билгесен

Предметны

Предметның эшен, хәрәкәтен

# Кем игътибарлы?

| Боерык фигыль | Хикәя фигыль | Шарт фигыль | Исем фигыль | Инфинитив | Сыйфат фигыль | Хәл фигыль |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

**Табышмаклар:** 1. Куян чапканда ник артына әйләнеп карый?

2. Аягы юк – китәр, җибәргән җиргә җитәр, кушкан йомышны үтәр.
3. Акыллыга әйттм, - уйлады да белде
   Акылсызга әйттем,- тыңлады да көлде.
4. Базарда табылмас, үлчәүдә үлчәнмәс, аннан да татлы булмас.

# Грамматик лото

1. Малайлар командасына унау җыелган идек, ярыш буласы көнне генә тагын берәү өстәлде. 2. Безнең ишегалдындагы ике катлы йортка яңа гына күчеп килгән малай, диделәр.  3. Үзен күрү түгел әле исемен дә ишеткәнем юк иде. 4.  Зөлфия бөтенебезне тезеп, исемлек барлаганда гына белеп алдым – Мансур атлы икән. 5. Быел бишенче сыйныфны тәмамлап, алтынчыга күчкән. 6. Яшьтәш. 7. Көзгә бергәләп укый башлыйбыз икән.

Ия


ЮА.керІНьзн т.

Т.к.

Жыю саны

Тәртип саны

# Сораулар



**1 нче сыйныф**

**А өлеше**

**А1 Фигыльнең сорауларын күрсәт.**

1. кем? нәрсә?
2. нишли?
3. нинди?

**А2  Фигыльләр булган рәтне күрсәт.**

1. мәктәп, укучы;
2. яза, укый;
3. ак, тәмле .

**А3  *Башлана* сүзенә сорау куй.**

1. нәрсә?
2. нишли?

**А4  *Ятмый* сүзенә сорау куй.**

1. нишли?
2. нишләми?

**В өлеше**

**Укы.** ***Менә кыш килде. Җирне ак кар каплады. Балалар чанада шуалар. Малайлар чаңгыда йөриләр.***

В1 Хикәя ничә җөмләдән тора?

В2 Хикәядән **нишләде?** соравына җавап биргән сүзләрне күчереп яз.

В3 Хикәядән **нишлиләр?** соравына җавап биргән сүзләрне күчереп яз.

**С өлеше**

**Бирем.** Хикәядә кайсы ел фасылы турында сүз бара шуны язып куй.

**2 нче сыйныф**

*А өлеше*

**А1 Фигыль нәрсәне белдерә?**

1. предметны белдерә;
2. предметның эшен, хәрәкәтен белдерә;
3. пердметның билгесен белдерә.

**А2 Фигыль нинди сорауларга җавап бирә?**

1. кем? нәрсә?
2. нинди? кайсы?
3. нишли? нишләде?

**А3 Юклыкта килгән фигыльләрне күрсәт**

1. яза, укыды, киләчәк;

утырмый, бармады, күрмәячәк.

**А4 Фигыль ничә заманда килә?**

2

3

**А5 Тыңлыйбыз фигыле кайсы заманда килгән?**

киләчәк заман,

хәзерге заман,

үткән заман.

**А6 Укыячак фигыленә сорау куй**.

нишли?

нишлиләр?

нишләячәк?

***В өлеше***

**Укы.** ***Кайбер укучылар куян үстерәләр. Тик аларны дәрес ашатмыйлар. Шунлыктан куяннар еш авырый. Куяннар кишер, кәбестә ярата.***

В1 Хикәя ничә җөмләдән тора?

В2 Текстта ничә фигыль бар?

В3 Хикәядән берлек сандагы фигыльне язып ал.

В4 Юклыкта килгән фигыльне язып ал.

***С өлеше***

**Бирем** Куян турында белгәннәрегезне языгыз.

**3 нче сыйныф**

А өлеше

А1 Фигыль нәрсәне белдерә?
предметның билгесен белдерә;
предметны белдерә;
предметның эшен, хәрәкәтен белдерә.
А2 Фигыльнең юклык кушымчасын күрсәтегез
-ма/-мә; -мый/-ми;
–ды/-де, -ты/те.
–лар/-ләр, -нар/-нәр.
А3 Фигыльнең ничә заманы бар?
2
3
4
А4 Үткән заманда килгән фигыльләрне күрсәтегез
язмадым, утырттык,
язмыйм, утыртабыз,
язачамын, утыртырбыз.
А5 Фигыль нәрсәләрдә төрләнә?
килешләрдә,
зат-санда, заманда.
А6 **Киләсең** фигылнең зат-санын күрсәтегез
III зат, берлек санда;
I зат, күплек санда,
II зат, берлек санда.

В өлеше

**Укы.** Болында сусыл үләннәр үскәннәр. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Болында ат көтүе йөри. Атлар яшел үлән ашый, чишмә суын эчә.
В1 Текстта ничә җөмлә бар?
В2 Үткән заманда килгән фигыльләрне язып ал.
В3 берлек санда килгән фигыльләрне язып ал.

С өлеше

**Бирем** Ат кешеләргә нинди файда китерә? Шул турыда яз.

**4 нче сыйныф**

А өлеше

А1 Фигыльнең дөрес билгеләмәсен күрсәтегез
1) эшен, хәрәкәтен, хәлен белдерә торган сүзләр;
2) предметны белдерә торган сүзләр;
3) предметның билгесен белдерә торган сүзләр.
А2 Боерык фигыль
предметның эше, хәле турында хәбәр итә;
эш кушу, чакыру, өндәүне белдерә.
А3 Хикәя фигыль
эш кушу, чакыру, өндәүне белдерә;
предметның эше, хәле турында хәбәр итә.
А4 II зат, күплек санда килгән боерык фигыльләрне күрсәтегез
барасыз, килмәдегез, язасыз;
карагыз, укыгыз, ятлагыз;
язачаксыз, китәрсез, пешерерсез.
А5 **Кызлар шаян такмаклар әйттеләр** җөмләсендәге фигыльнең заманын, зат-санын күрсәтегез.
Үткән заман, III зат, күплек сан;
Хәзерге заман, III зат, күплек сан;
Киләчәк заман, III зат, күплек сан.

В өлеше

**Укы.** Кыш.

1 Салкын кыш килде. 2 Кышкы салкын җил карларны очырта. 3 Карлы, бозлы җилләр агач башларын селкетә. 4 Урман шаулый. 5 Кызыл шарфлы эшчән тураннар җилне сизмиләр. 6 Алар агачларның җыерчыклы кәүсәсеннән зарарлы кортларны чүплиләр. 7 Чаңгычылар да җилдән курыкмаган. әнә алар, кар өстендә эз калдырып, чаңгы шуалар.

В1 Үткән заманда килгән фигыльләрне язып алыгыз.
В2 Берлек санда килгән фигыльләр булган җөмләләрнең номерын күрсәтегез.
В3 Хәзерге заман күплек санда килгән фигыльләрне язып алыгыз.
В4 Юклык формасында килгән фигыльләр булган җөмләләрнең номерын күрсәтегез.

С өлеше

Текстка нигезләнеп “Минем ял көнем” дигән хикәя языгыз.

**7 нче сыйныф**

А өлеше

А1 Фигыль, нигездә, җөмләнең нинди кисәге була?

хәбәр;

теләсә кайсы исәге;

хәл һәм аергыч;

А2 Барлык фигыльләрдә дә очрый торган билгеләрне әйтегез

өч зманда килү;

зат белән төрләнү;

сан белән төрләнү;

барлык һәм юклык.

А3 Кайсы фигыльләр өч заманда да килә?

хикәя һәм сыйфат фигыльләр;

барлык фигыльләр дә;

шарт, исем, сыйфат фигыльләр;

инфинитив, боерык һәм сыфат фигыльләр.

А4 Кайсы фигыльләр сан белән төрләнми?

1)исем фигыльләр;

2) хәл фигыль белән инфинитив;

3) хәл һәм шарт фигыльләр;

4) боерык фигыль белән инфинитив.

А5Бу җөмләдә нинди фигыльләр бар?

*Без яшәгән авыл борыла-борыла аккан Агыйдел буена урнашкан.*

өч сыйфат һәм бер хәл фигыль;

өч хикәя һәм бер хәл фигыль;

ике хикәя, берәр сыйфат һәм хәл фигыль;

ике сыйфат, берәр хикәя һәм хәл фигыль

А6 Кайчан сыйфат фигыль җөмләнең теләсә айсы кисәге була?
сыйфатланмышы белән килгәндә;
сыйфатланмышы урынында килгәндә;
үткән заманда булганда;
киләчәк заманда булганда.
А7 Бу фигыльләр кайсы төркемчәгә карый?
*Укып, сөйли-сөйли, кайткач, килгәнче.*
хәл фигыль;
шарт фигыль;
хикәя фигыль;
инфинитив.
А8 Фигыльнең башлагыч формасы дип нәрсә атала?
боерык фигыль;
II зат хәзерге замн хикәя фигыльнең берлге;
Фигыльнең тамыр, ясалма яки тезмә нигезе:
Тамыр яки ясалма боерык фигыльнең II зат берлеге.
А9 Бу фигыльләр ничек ясалганнар?
*Эшлә, аңла, чибәрлә, матурла.*
исемнәргә *-ла/-лә* кушымчалары ялганып;
сыйфатларга *–ла/-лә* кушымчалары ялганып;
исем һәм сыйфатларга *–ла/-лә* кушымчалары ялгнып;
сүзләргә *-ла/-лә* кушымчалары өстәлеп.

# Контроль эш күрсәткечләре

| № | Укучының исем, фамилиясе | A1 | A2 | ... | ... | А бирeме | B1 | B2 | ... | B бирeме | C | Барлыгы (A+B+C) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Абиняева Д. | 1 | 0 | 1 | 0 | 28 | 0 | 0 | 1 | 2 | 1 | 54 |
| 2. | Минаев Д. | 0 | 1 | 1 | 1 | 20 | 1 | 1 | 0 | 2 | 1 | 26 |
| ... | .... | | | | | | | | | | | |
| ... | ..... | | | | | | | | | | | |
| | ИТОГО | 20 | 24 | 8 | ... | ... | ... | ... | ... | ... | ... | ... |